ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Хезмәт ветераны” исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында” 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1 статья. **“Хезмәт ветераны” исеме бирелә торган затлар**

1. “Хезмәт ветераны” исеме түбәндәгеләргә бирелә:
1) СССР яисә Россия Федерациясе орденнары яисә медальләре белән бүләкләнгән, йә СССРның яисә Россия Федерациясенең мактаулы исемнәренә лаек булган, йә Россия Федерациясе Президентының мактау грамоталары белән бүләкләнгән яисә Россия Федерациясе Президенты рәхмәтенә лаек булган, йә эштәге (хезмәттәге) казанышлар һәм эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә (икътисад тармагында) кимендә 15 ел дәвамында эшләгән (хезмәт иткән) өчен ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнгән һәм пенсия билгеләү өчен ирләргә кимендә 25 ел һәм хатын-кызларга кимендә 20 ел итеп исәпләнә торган хезмәт (иминият) стажы яисә календарь буенча исәпләгәндә тиешле еллар эшләгәнгә пенсия билгеләү өчен кирәкле тиешле эшләгән еллары булган затларга;
2) хезмәт эшчәнлеген Бөек Ватан сугышы чорында балигъ булмаган яшьтә башлаган һәм ирләр өчен кимендә 40 ел һәм хатын-кызлар өчен кимендә 35 ел хезмәт (иминият) стажы булган затларга.
2. Әлеге Законда “Хезмәт ветераны” исеме бирелү хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгалары дигәндә, федераль башкарма хакимият органнары, башка федераль дәүләт органнары, дәүләт корпорацияләре тарафыннан гамәлгә куелган һәм алар белән бүләкләү күрсәтелгән органнар һәм оешмалар билгеләгән тәртиптә башкарылган, эштәге (хезмәттәге) казанышлар һәм эшчәнлекнең тиешле

өлкәсендә (икътисад тармагында) кимендә 15 ел дәвамында эшләгән (хезмәт иткән) өчен ведомство бүләкләре дип аңларга кирәк.";

2) 2 статьяда:

а) 2 өлешнең 1 һәм 2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) СССР яисә Россия Федерациясе орденнары яисә медальләре белән бүләкләнүне, йә СССРның яисә Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре бирелүне, йә Россия Федерациясе Президентының мактау грамоталары белән бүләкләнүне яисә Россия Федерациясе Президентының рәхмәт белдерүен, йә "Хезмәт ветераны" исеме бирелү хокукын бирә торган ведомство аерымлык тамгалары белән бүләкләнүне;

2) пенсия билгеләү өчен ирләргә кимендә 25 ел һәм хатын-кызларга кимендә 20 ел итеп исәпләнә торган хезмәт (иминият) стажы яисә календарь буенча исәпләгәндә тиешле еллар эшләгәнгә пенсия билгеләү өчен кирәкле тиешле эшләгән еллары булуны.";

б) 3 өлешнең 2 пунктында "хезмәт стажы" сүзләрен "хезмәт (иминият) стажы" сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 статьяның 1 өлешендә "20 көн эчендә" сүзләрен "биш эш көне дәвамында" сүзләренә алмаштырырга;

4) 4 статьяның 2 өлешендә "көннән соң 10 көн эчендә" сүзләрен "көннән алып 14 эш көне дәвамында" сүзләренә алмаштырырга;

5) 5 статьяның 1 өлешендә "өч көн эчендә" сүзләрен "биш эш көне дәвамында" сүзләренә алмаштырырга;

6) 6 статьяның 3 өлешендә "көннән соң өч көн эчендә" сүзләрен "көннән алып биш эш көне дәвамында" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

"Хезмәт ветераны" исемен бирү тәртибе һәм шартлары турында" 2011 елның 30 июнендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган редакциясендәге 1 статьясының 2 өлешендә расланган тәртиптә билгеләнгән хезмәттәге ведомство аерымлык тамгалары белән 2016 елның 30 июненә бүләкләнгән гражданнарга, пенсия билгеләү өчен ирләргә кимендә 25 ел һәм хатын-кызларга кимендә 20 ел итеп исәпләнә торган хезмәт (иминият) стажы яисә календарь буенча исәпләгәндә тиешле еллар эшләгәнгә пенсия билгеләү өчен кирәкле тиешле эшләгән еллары булган очракта, "Хезмәт ветераны" исеме бирелү хокукы сакланып кала дип билгеләргә.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 9 июле
№ 56-ТРЗ